**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Кече Тормы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**02 декабрь, 2021 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Кече Тормы авылында гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең Кече Тормы авыл җирлеге территориясендә 2022 елда гражданнарның үзара салымын 1000 (бер мең) сум күләмендә кертергә.
2. Гражданнардан алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга һәйкәл төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Тормы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. https://tetushi.tatarstan.ru/

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Тормы авыл җирлеге башлыгы** **Н.Г. Салихов**